РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

01 сентябрь 2026 ел

Буа шәһәре

№ 3-19

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2020 елның 30 декабрендәге 8-6 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы (28.12.2025 ред) Федераль законнар нигезендә, муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатыннан, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районыны Советы карар чыгарды:

1. «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2020 елның 30 декабрендәге 8-6 номерлы карарына ( 23.04.2021 № 2-11, 09.07.2021 № 2-14, 28.06.2024 № 2-62 ред) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Карарга 1 нче кушымтаның 5 статьясындагы 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Депутатка үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә гамәлгә ашыру өчен эш бирүче тарафыннан эш урынын (вазыйфасын) саклап калып эшләүдән азат ителү, дәвамлылыгы Россия Федерациясе субъекты законы нигезендә муниципаль берәмлек уставы белән билгеләнә торган һәм аена ике эш көненнән кимрәк һәм алты эш көненнән артыграк була алмаган чорга гарантияләнә.»

1.2. 1 нче кушымтаның 2 статьясындагы 3 өлеше түбәндәге редакциядә:

«Депутатның вәкаләтләре ул сайланган көннән башлана һәм яңа чакырылыш Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының (алга таба - Совет) тулы хокуклы составтагы беренче утырышын уздырган көннән туктатыла.»

2. Әлеге карар басылып чыккан вакыттан законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru адрес буенча һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Буа муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://buinsk.tatarstan.ru) интернет челтәрендә урнаштырылырга тиеш.

3.Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль район башлыгы,
Совет рәисе Р.Р. Камартдинов